

# Габдулла Тукай

Еллар узган саен бу исем ешрак телгә алына. Тукай шәхесе елдан ел калкурак күренә. Татар халкының даһи улына якты дөньяда озак яшәү насыйп булмый. Әмма  ул башкарган эшләр гасырларга тиң.

Димәк, Тукай яши, Тукай – үлемсез

- Презентацияне  төзеде:
- Татарстан Республикасы Нурлат районы Киекле урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы Абдрахманова Гүзәлия Хөснетдин кызы

# Тукай - бөек татар шагыйре.



**Тарих бик күп исемнәрне белә,**
**Бөек шәхесләргә дөнья бай.**
**Иҗтиһады белән маяк булып,**
**Мәңге яши, яшьни яшь Тукай!**



Мөхәммәтгариф – Габдулланың атасы.



Мәмдүдә - Габдулланың анасы.

# Син мәңгелек халкым күңелендә



**Кушлавыч. Шәрифә карчык**




**Өчиле.**

**Зиннәтулла бабай**



**Казан.**

**Мөхәммәтвәли һәм Газизә гаиләсе**



**Кырлай.**

**Сәгъди абзый, Зөхрә апа**



**Җаек.**

**Галиәсгар (җизнәсе)**

***И күңелнең шаулап***

***чишмәдән сафрак***

***чагы!***

***И гомернең нурланып***

***үскән яшел яфрак***

***чагы!***

***Г.Тукай***






Кечкенә Габдулла Зиннәтулла бабасы белән

“Исемдә калганнар” дигән истәлегендә Тукай болай яза:

*“... фәкыйрь вә шуның өстенә әллә ничә авызлы булган гаилә эченә мин ятим бала булып килеп кергәнмен.”*




Кечкенә Апуш
һәм Сәгъди абый

**Алты яшьлек Тукай Кырлай авылына, Сәгъди абзый белән Зөхрә апа гаиләсенә килеп керә. Кырлайдагы тормышы яшь Тукайның күңелендә иң җылы истәлекләр калдыра.**




Галиәсгар Госманов йорты

**1895 елда Габдулла Җаек шәһәренә әтисе ягыннан туган Газизә апасы һәм аның ире Галиәсгар җизнәсе янына күчеп килә.**






Җаек–Г.Тукайның журналист һәм шагыйрь буларак ныгыган урыны. Фикер” газетасының беренче санында ук үзенең әсәрләрен бастыра. “Әлгасрел – җәдит” һәм “Уклар” кебек журналларда күпләгән шигырь, мәкалә һәм фельетоннар белән чыгыш ясый. Шагыйрь үзенең төп эше хаклык, халык мәнфәгатьләре өчен көрәш һәм дөреслекне чагылдыру булырга тиеш, дигән караштa торды.

# Г.Тукай. Уральскидагы иптәшләре янында. 1907 ел






“Әльислах” газетасы идарәсе урнашкан бина.

Уңнан сулга: Г.Тукай, И. Әмирхан, Ф. Әмирхан, К.Бәкер, В. Бәхтияров.







**1907** елда Тукай Казанга кайта

Казанга кайткач, Г. Тукай әдәбият мохитенә чума. Г. Камал белән бергә “Яшен”, “Ялт – Йолт” журналларын оештыра, Ф. Әмирхан нәширлегендә чыга торган, “Әл – ислах” гәзитендә еш языша. Казанда аның иҗаты тагын да үрчемле, нәтиҗәле була, сәнгатьчә югары дәрәҗәдә язылган күпчелек әсәрләре шушында туа.




Г.Тукай һәм Ф. Әмирхан.(1908 ел)




“Ялт-Йолт” журналының тышлыгы




“Яшен” журналының тышлыгы




**Габдулла Тукайның татар телендә чыккан кайбер җыентыкларының тышлыклары.**

*Кечкенә генә булса да үз фатиры булмаганга күрә, ул “Болгар” һәм “Амур” кебек кунакханәләрдә яшәргә мәҗбүр булган. Шушы җайсызлыкларга үч итеп, үҗәтләнеп иҗат иткән, каләмен үләренә бер тәүлек кала гына читкә куйган.*



Казанда “Болгар” номерлары



Тукайның Клячкин хастаханәсендә үткәргән айдан аз гына артыграк вакыты – гомеренең гаҗәпкә һәм таңга калдырырлык соңгы сәхифәсе.

**1913 ел, 1 апрель**
**(соңгы фоторәсеме)**

***Буын арты буын алмашыныр,***

***Гасыр арты узар гасырлар,-***

***Шигъриятең өчен рәхмәт әйтеп,***

***Язлар сиңа гөлләр ташырлар.***

***Халык моңы синең моңың булды,***


***Халык күңеле-синең күңелең.***

***Ил гомере,халык гомере кебек***

***Озын булсын ,Тукай,гомерең !***

Шәүкәт Галиев





Дөньяда бик аз булыр
чын шагыйрь,

Габдулладай;

Ул-караңгы төндә
яктырткан матур ,

ак тулган ай.

*Шәйхзадә Бабич*


# Тукай ядкәрләре



Музей каршындагы Тукай һәйкәле



Габдулла Тукайның балалык дәвере



Г.Тукайның кара савыты
һәм язуы




Г.Тукайның
карандаш савыты




*"Габдулла Тукай"* теплоходы



**Казанда Г.Тукай исемендәге урамның гомуми күренеше.**



**Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе.**